Кукмара муниципаль районы
Пычак авыл җирлеге
Советы

# КАРАР

«23» гыйнвар, 2026 ел № 2

Гектарларда яисә баллогектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законының 15 статьясындагы 2.1 пункты, 19.1 статьясындагы 8 – 11 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гектарларда яисә балло-гектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә күрсәтелгән җир өлешләренең зурлыкларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1475 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Пычак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан 2025 елның 25 декабрендәге өземтәләргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Пычак авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Кадастр номеры 16:23:000000:367, мәйданы 630176 м² булган җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукында өлешләр күләмен билгеләү нәтиҗәләрен расларга, урнашкан урыны кишәрлек чикләрендә урнашкан ориентирга карата билгеләнгән. Ориентирныж почта адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Пычак авыл җирлеге, тер. Пай җирләре, җир кишәрлеге 378, җирләр категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, рөхсәт ителгән куллану төре: авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен, гектарларда күрсәтелгән, гади ялгыз вакланма рәвешендә, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Пычак авылы башкарма комитетына, әлеге карар басылып чыккан көннән соң 30 көн узгач, Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш.Нафиков

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Советының 2026 елның «23» гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

Кадастр номеры 16:23:000000:367 булган җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге гектарларда яисә балл-гектарларда күрсәтелгән җирләрдән гади ялгыз вакланма рәвешендә өлешләр күләмен билгеләү нәтиҗәләре

(2025 елның 23 декабренә булган торышына карата)

Җир кишәрлегенең мәйданы җирле үзидарә органы тарафыннан Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан (алга таба – ЕГРН) алынган өземтә нигезендә (бөтен кыйммәткә кадәр түгәрәкләп) 63

| т/б № | хокукны дәүләт теркәвенә алу № һәм датасы (шулай ук, әгәр № һәм дәүләт теркәвенә алу датасы туры килсә, дәүләт теркәвенә алу вакыты) җирле үзидарә органы тарафыннан ЕГРНнан алынган өземтә нигезендә | Җирле үзидарә органы тарафыннан ЕГРНнан алынган өземтәдәге җир өлеше күләме турында белешмәләр (кыйммәте) | 3 нче графада күрсәтелгән, бөтен кыйммәткә кадәр түгәрәкләнгән җир өлешенең зурлыгы | 3 нче графада күрсәтелгән өлешнең күләме ничек күрсәтелгән (гектарларда яки балло-гектарларда) | Гади ялгыз вакланма (вакланманы кыскартуны исәпкә алмыйча) | **Гектарларда яки баллогектарларда гади ялгыз вакланма рәвешендә (вакланманы кыскартуны исәпкә алып) күрсәтелгән, белешмәләре ЕГРНга кертелергә тиешле җир өлешенең зурлыгы** | Хокук иясе турында белешмәләр: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы; юридик затның тулы исеме, ОГРН, ИНН. | ЕГРН га белешмәләрне гади ялгыз вакланма рәвешендә кертү турындагы мәгълүмат ("+" – 7 графасы нигезендә кертелгән; " - " – 7 графасы нигезендә кертелмәгән) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | № 16:23:000000:367 16/262/2025-6 17.01.2025 датасыннан | 4,50 | 5 | Гектарларда | 5/63 | 5/63 | Миннегалиев Азат Миннехан улы 26.08.1982 | | |
| 2 | № 16:23:000000:367-16/261/2022-4 от 18.08.2022 датасыннан | 4,50 | 5 | Гектарларда | 5/63 | 5/63 | Шаймарданова Асия Магсум кызы, 03.03.1967 | | |
| 3 | № 16-16/024-16/117/001/2016-5795/1 от 23.08.2016датасыннан | 4,50 | 5 | Гектарларда | 5/63 | 5/63 | Галимухаметов Айдар Наил улы 29.09.1966 | | |